**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423181, РТ Новошешминский район с. Ленино, ул. 40 лет Победы д. 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423181 РТ Яңа Чишмә районы ,Ленино авылы, Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАРЫ

2019 елның 29 октябре № 2

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында Үзәк урам буенча 47-81 (так як) һәм 12-80 (җөп ягы), Совет урамы буенча 121-129 нчы йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 12 ноябрь көнне 12.00 сәгатькә Ленино авылында Үзәк урамының 84 нче йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында Совет урамы буенча 1-43 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 13 ноябрь көнне 14.00 сәгатькә Ленино авылында Совет урамы, 15 нче йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында Җиңүнең 40 еллыгы урамы буенча; Кул арты урамы; Үзәк урам буенча 1/1 - 45 (так як), 6,10 йортлар; Совет урамы буенча 44-118 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 14 ноябрь көнне 14.00 сәгатькә Ленино авыл мәдәният йортында(Үзәк урам, 89А нче йорт) уздырырга дип билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен Ленино халкы исемлеген бүлеп сайлау тәртибе территориаль бүленеш буенча башкарылырга тиеш

5. Гражданнар җыенын уздыру һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
“2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, 1 нче группа инвалидлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:
- Боек Җиңунең 40 еллыгы урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- роторлы косилка һәм запас·частьләр сатып алу;
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру)

“РИЗА” "КАРШЫ"

7. Әлеге карарны «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында. http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы В.М. Веретенников